РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА**

**СТАРОКАЗЕЕВСКОГО**

**сельского поселения**

***Камско-Устьинского***

**муниципального района**

ул. Центральная, 7, д.Караталга, 422834
тел. (8-843-77)30-4-16, факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

***Кама Тамагы***

**муниципаль районы**

**ИСКЕ КАЗИЛЕ**

**авыл җирлеге**

**БАШЛЫГЫ**

Үзәк урамы, 7 , Каратал авылы, 422834,
тел. (8-843-77)30-4-16 , факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**03 декабрь 2019 ел** **№ 57**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Бишалаб авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама-Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Бишалаб торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елнын 14 нче декабренэ 11.00 сэгатькэ билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенә кергән Бишалаб торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 2020 елда 1800 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

Бишалаб авылында юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- торак пункт территорияләрен төзекләндерү, шул исәптән чүп үләннәрен чабу;
- күмү урыннарын тәртиптә тоту һәм ремонтлау, зиратка капка кую;
- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү.

« ӘЙЕ»  «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе  И.Х.Сәгдиев